# Яшьлек

Минзәлә шәһәре гимназиясе
Киләчәкнең башы - бүгенгедә
1998

Май,, 2017 ел





## Сау бул,мәктәп!

## Атна шәхесе - Лилия!



## Батырларга мәңгелек дан!

# Батырларга мәңгелек дан!

1941 нче елда безнең илебезгә фашист гаскәрләре басып кергән. Ул вакытта сакларга бөтен халык бердәм булып күтәрелгән.



Дошманга каршы кырыс көрәш 1418 көн һәм төн дәвам итте. Җиңү кыйммәткә төште. Миллионнарча ватандашлар сугыш кырларында башларын салды, партизан берләшмәләрендә һәлак булды, концлагерьларда җәфа чикте. Быел халкыбыз 73 нче тапкыр Җиңү көнен билгеләп үтте. Ә сугыш үзенең ачлыгы-ялангачлыгы, мәрхәмәтсезлеге һәм үлем ачысы белән 1941 нче елның 22 нче июненә барып тоташа.

Җиңүгә килү юлы җиңел түгел, әлбәттә. Ул көнне күрү һәркемгә насыйп та булмаган. Күпләр сугыш кырларында ятып кала, фашист төрмәләрендә, концлагерьларда һәлак була, ачтан үлә,ләкин шунысын истә тотыйк бу көн халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас көн булып уелып кала. Хәзерге вакытта да 9 нчы Май Җиңү көне буларак билгеләп үтелә.



Тик шулай да, күпме еллар узса да, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр.

Без ел саен 9 нчы Май көнендә Бөек Җиңүгә багышланган бәйрәм парадын карарга барабыз. Анда күкрәкләренә орден-медальләр таккан чал чәчле ветераннарны күргәч, безгә тыныч тормыш бүләк иткән өчен рәхмәт хисе уяна. Чал чәчләреннән сыйпыйсы, дөньядагы иң матур сүзләр белән юатасы, мең рәхмәт әйтәсе килә аларга! «Үлемсез полк» акциясе – 9 май бәйрәменең тагын бер күркәм традицияләренең берсе. Халык сугышта катнашкан, яу кырында ятып калган туганнарының истәлекле фотосурәтләре белән урамга чыга. Һәм шуны истә тотарга кирәк, «Үлемез полк» йөрешендә катнашыр өчен, беркайда да теркәлү узарга кирәкми. Моның өчен бары тик теләгең булуы гына мөһим!





Низамова Сөмбел

# Атна шәхесе- Әкбәрова Лилия!

Атна шәхесе- Әкбәрова Лилия!



Бу айның шәхесе– Лилия! Ул бик мәрхәмәтле, позитив, креатив һәм актив бала. 🌸
Лилия 21 нче апрель көнне Казан шәһәренә “Илһам” бәйгесенә юл тотты һәм анда җиңу яулады. Аңа бүләккә сертификат һәм кубок тапшырдылар. Без синең өчен бик шатланабыз һәм горурланабыз!

**<u>Туган көне : 23.04.99</u>**
**<u>Ф.И.О.: Әкбәрова Лилия Илдар кызы</u>**
**<u>Яраткан фильмы: Великий Гэтсби</u>**
**<u>Яраткан ризыгы: чечевица</u>**

**-Хәерле көн, Лилия!**
-Привет, Айзилә.
- **Әгәр дә “вакыт машинасы”нә утырып, үткәнгә кайтып булса, син нәрсә үзгәртер идең?**
- Сәләткә иртәрәк барыр идем һәм укый башлар идем.
- **Тормышыңда синең өчен ни мөһим?**
**-** Тормышта үз урыныймны табу.
- **Синең тормышыңда берәр нинди “безбашенный” поступок бар идеме?**
**-** (көлә) Без бер тапкыр кызлар белән укытучыларның фотоларына мыек ясаган идек.
- **Син үзеңне уңышлы кеше дип саныйсыңмы?**
**-** Әйе, имназия дәрәҗәсен алсак, әйе, уңышлы, чөнки мин көн саен үземне төрле яктан үстерәм.
**- “Эх, туган көн, туган көн...” дигән җырны дәвам ит.**
**-** Иң куркыныч булган көн (көлә), чөнки мин туган көнемне яратмыйм.
**- Нинди 3 әйбердән куркасың?**
**-** Аллаһ, елан һәм тормыш мәгънәсен югалтудан.
- **Кечкенә чагыңда нинди профессия сайлыйсың килгән иде һәм хәзерге вакытта син ул профессияне сайларга әзерме?**



**-** Стоматолог, юк, хәзер сайлыйсым килми, чөнки мин үземнең тормышымны медицина белән бәйлисем килми.
- **Җәйгә планнарың нинди?**
**-** Экзаменнарны уңышлы гына бирергә һәм сәләткә барып кайтырга.
- **Журналистика белән күптәннән шөгелләнәсеңме?**
**-** Хм… якынча 2 ел.
**- Рәхмәт, Лилия!**


Җәмилова Айзилә

# Яз һәм Хезмәт бәйрәме



1 нче май - күпләрнең яраткан бәйрәме

Язның соңгы ае булуга карамастан, нәкъ шушы бәйрәм җылылыкның һәм матурлыкның башы булып тора. Ә кемнәрдер өчен бу бәйрәм - көндәлек мәшәкатьләрдән арынып, дуслар,туганнар белән аралашу,ял итү бәйрәме. Бу бәйрәмне яратсак та, без аның килеп чыгу тарихын беләбезме соң? Өлкән буын кешеләре бу бәйрәмне Советлар Союзы чорыннан ук бәйрәм итеп килсә, хәзерге буын өчен бу бәйрәм бары тик өстәмә ял дигәнне генә аңлата.

1886 елда Чикаго эшчеләре 15 сәгатьлек эш көнненән 8 сәгатьлек эш көне сорап забастовка игълан итәләр. Нәкъ шушы эшчеләр Майа патшабикәсенә табынганнар. Шуның аркасында язның соңгы ае Май дип аталган, ә бу айның 1 нче көнендә бәйрәмнәр уздырылган. 1890 елның 1 маенда Россия комммунистлар беренче тапкыр бу бәйрәмне бәйрәм итәләр, бу вакыйга Варшавада була.

Бу бәйрәмне АКШ һәм Россия гена түгел,ә 142 ил бәйрәм итә. Бигрәк тә бу бәйрәмне шушы илләр хөрмәт итә:

- Испании;
- Германии;
- Швеции;
- Греции;
- Франции;
- Италии;
- Голландии.



Германиядә 1 нче май көнен ярминкәләр, җырлар,уеннар белән уздыралар. Шулай ук бу көнне гашыйк парлар кызның тәрәзә төбендә агач утырталар.

Франциядә бу бәйрәмнең символы булып ландыш чәчәге тора. Нәкъ шушы чәчәк бәхет билгесен аңлата, французлар бер-берсен котлыйлар һәм чәчәкләр бирәләр.




Италиядә исә бу көнне Майа патшабикәсен искә алып чәчәкләр фестивале уздырыла.

Шулай итеп, 1 нче май бәйрәме – төрле милләт кешеләрен берләштерә һәм күпләргә уңай эмоцияләр бирә

# Онытылмаслык мизгелләр

Онытылмаслык мизгелләр





















*Архив гимназии...*

# Туган көн- гомер бәйрәме...

**Укытучылар:**
**Раушания Шамил кызы (05.05)**
**Разина Байчурин кызы ( 17.05)**
**5 нче сыйныф:**
**Крашова Рузалина (16.05)**
**6 нчы сыйныф:**
**Шәрипов Камил (1.05)**
**8 нче сыйныф:**
**Норхужаев Шерхан (06.05)**
**10 нчы сыйныф:**
**Шәрифуллин Айнур (14.05)**
**Шәрафиева Зилә (19.05)**









**Баш мөхәррир** —Низамова Сөмбел
**Әдәби консультант-** Җәмилова Айзиля
**Бүлек мөхәррирләре** - Хәбирова Наилә
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745